Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
Түбән Чыршылы авыл җирлегенең
Түбән Чыршылы торак пункты гражданнар җыены
КАРАРЫ

2022 елның 19 ноябре № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы торак пункты гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 19 ноябрендә узган «Сез 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Түбән Чыршылы авыл җирлеге Түбән Чыршылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, сроклы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме: җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, инвалидлар өчен социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы һәм күрсәтелә торган хезмәтләр күрсәтү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру: җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, инвалидлар өчен социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы һәм күрсәтелә торган хезмәтләр күрсәтү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

Түбән Чыршылы торак пунктында урам утларына техник хезмәт күрсәтү;

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Түбән Чыршылы торак пунктындагы Тукай урамы, Плетеная урамында вак таш җәелгән юллардагы чокырларны ремонтлау;

Түбән Чыршылы торак пунктында Калмык, Мельничная, Мокрый Куст, Озерная, Плетеная, Совет, Тукай, Үзәк урамнарындагы юлларны кардан чистарту

« РИЗА» «КАРШЫ» соравы буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 500 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 255.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 255 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлеге составына керүче Түбән Чыршылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Түбән Чыршылы авыл җирлеге Түбән Чыршылы исемендәге поселок территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, сроклы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш,, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме: җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, инвалидлар өчен социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы һәм күрсәтелә торган хезмәтләр күрсәтү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

Түбән Чыршылы торак пунктында урам утларына техник хезмәт күрсәтү;

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Түбән Чыршылы торак пунктындагы Тукай урамы, Плетеная урамында вак таш җәелгән юллардагы чокырларны ремонтлау;

Түбән Чыршылы торак пунктында Калмык, Мельничная, Мокрый Куст, Озерная, Плетеная, Совет, Тукай, Үзәк урамнарындагы юлларны кардан чистарту сораулары буенча карарны кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Түбән Чыршылы авылы, Түбән Чыршылы авылы административ бинасында-Үзәк урам, 105 йорт, балалар бакчасы бинасында -Совет урамы, 8 йорт, Үзәк урам, 23 йорт буенча, ФАП бинасында-Мельничная урамы, 23 йорт , Югары Чыршылы авылында-авыл клубы бинасында-Горная урамы, 27 йорт, Мордва Ивановка авылында Совет урамы 13 йорт буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Н.Я. Хәйруллина